ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　КАРАР

от 26.07.2019　　　　№ 1175

**“2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү” муниципаль программасын раслау турында**

“Энергия саклау турында һәм энергетиканың нәтиҗәлелеген күтәрү хакында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында”, 2009 ел, 23 нче ноябрь, 261-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү максатында, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 ел, 6 нчы октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. “2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү” муниципаль программасын расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Афанасьев А.П.ка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе　　　　Д.Ф. Шәйдуллин

1 нче кушымта

Расланган
ТР Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты
карары белән
26.07.2019 № 1175

“2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү”
**муниципаль программасы**

2019 ел

Эчтәлек

Программаның паспорты……………………………………………………………………2
1. Гомуми нигезләмәләр………………………………………………...……….5
2. Программаны тормышка ашыру өлкәсенә гомуми характеристика………….…….7
3. Программаның максатлары, бурычлары. Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары………...............................................................................................…………9
4. Проблеманы хәл итүнең төп юллары……………………………………..……….9
5. Программаны тормышка ашыру нәтиҗәләренә бәя бирү индикаторлары исемлеге……….............................................................................................……11
6. Энергетик ресурсларны куллануга характеристика…………….......……………...13
6.1. Биектау муниципаль районында җылылык белән тәэмин итү…………………..13
6.1.1. Төп күрсәткечләр.....………………………………………………………..14
6.1.2. Биектау муниципаль районында җылылык белән тәэмин итү системасы…....14
6.1.3. Биектау муниципаль районында җылылык белән тәэмин итүнең икътисади проблемалары ……………………………………………….…………….…15
6.2. Биектау муниципаль районында су белән тәэмин итү …..………………………15
6.2.1. Төп күрсәткечләр .....……………………………………………………......15
6.2.2. Биектау муниципаль районында су белән тәэмин итү системасы ..…………..16
6.3. Биектау муниципаль районында электр белән тәэмин итүнең төп күрсәткечләре ……………………….........…………………………………………………16
6.4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында газ белән тәэмин итүнең төп күрсәткечләре ………………………………………………….......17
7. Энергетика ресурсларын куллануның коммерцияле хисабы системасын оештыру………...............................................................................................................18
8. Энергетик ресурсларны кулланганда энергия саклау……………………………...19
8.1. Торак йортларда энергияне саклау……………………………………………...19
8.2. Бюджет өлкәсендәге оешмаларда энергияне саклау……….....…………………...20
8.3. Биектау районы торак-коммуналь хуҗалыгының энергетик нәтиҗәлелеген арттыру………..........................……………………………………………………22
9. Биектау муниципаль районының энергетик балансы һәм энергия саклау потенциалы………………………………..………………………………….22
10. Энергетик тикшерү һәм паспортизация.............……………………………..……23
10.1. Энергетик тикшерү һәм торак йортларны паспортизацияләү...…………..…….23
10.2. Энергетик тикшерү һәм социаль өлкә һәм муниципаль предпритиеләрне паспортизацияләү ………………..........……………………………………..…….25
11. Кулланыла торган электр егәрлеген киметү .............…………………………….25
12. Программаның пилот проекты буларак энергиянең традицион булмаган һәм кабат булдырыла торган чыганаклары ……………………………………………………26
13. Кулланучылар арасында аңлату эшләре алып бару……………………………...28
14. Программаны тормышка ашыруның оештыру-икътисади механизмнары………..29
14.1. Программа белән идарә итү системасы………...…………………………………..29
14.2. Программаны тормышка ашыруны контрольдә тоту…….……………...……….30

15. Программаны һәм планлаштырылган социаль-икътисади нәтиҗәлелекне ресурслар белән тәэмин итү ……………………………………...…………...………...32

## Программаның Паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | “2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү” муниципаль программасы (алга таба -Программа) |
| Программаны эшләп чыгару өчен нигез (хокукый һәм норматив тәэмин итү) | 1. “Энергия саклау турында һәм энергетиканың нәтиҗәлелеген күтәрү хакында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында”, 2009 ел, 23 нче ноябрь, 261-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>2. “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 ел, 6 нчы октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль закон<br>3. “Товарларның, хезмәтләрнең, эшләрнең энергетик нәтиҗәлелеге таләпләрен урнаштыру, муниципаль ихтыяҗлар өчен заказлар урнаштыруга кагыйдәләрен раслау турында”, 2009 ел, 31 нче декабрь, 1221 номерлы РФ Хөкүмәте карары;<br>4. ~~Постановление Правительства РФ от 31.12.2009 г. №1225 «О требованиях к региональным и муниципальным программам в области энергосбережения и повышения энергетической эффективности»;~~ “Энергия саклау өлкәсендә төбәк һәм муниципаль программаларга талапләр һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру турында”, 2009 ел, 31 нче декабрь, 1225 номерлы РФ Хөкүмәте карары;<br>5. ~~Распоряжение Правительства Российской Федерации от 1 декабря 2009г. №1830-р об утверждении плана мероприятий по энергосбережению и повышению энергетической эффективности; Распоряжение Кабинета Министров Республики Татарстан от 9 марта 2010 г. №356-р об утверждении Плана мероприятий по энергосбережению и повышению энергетической эффективности в Республике Татарстан.~~ Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Энергия саклау һәм энергия нәтиҗәлелеген күтәрү буенча чаралар планын раслау турында”, 2009 ел, 1 нче декабрь, 1830-р номерлы карары; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергия нәтиҗәлелеген күтәрү буенча чаралар Планын раслау турында”, 2010 ел, 9 нчы март, 356-р номерлы карары;<br>6. ~~Приказ Минэкономразвития РФ от 17.02.2010 г. № 61 «Об утверждении примерного перечня мероприятий в обеспечении энергосбережения и повышения энергетической эффективности, который может быть использован в целях разработки региональных, муниципальных программ в области энергосбережения и повышения энергетической~~ |

Отформатировано: татарский

Отформатировано: татарский

Отформатировано: татарский

| | |
|---|---|
| | эффективности»;РФ Икътисади үсеш Министрлыгының “Энергия саклау һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру өлкәсендә төбәк, муниципаль программаларны эшләү максатыннан кулланырга мөмкин булган, энергия саклау һәм энергетик нәтиҗәлелекне күтәрүне тәэмин итүдә якынча чаралар исемлеген раслау турында ”, 2010 ел, 17 нче февраль, 62 номерлы боерыгы;<br>7. РФ Икътисади үсеш Министрлыгының “Каршы куела торган шартларда дәүләт (муниципаль) учреждениеләр тарафыннан кулланыла торган ресурсларның киметү күләмен ачыклау тәртибе турында”, 2011 ел, 24 нче ноябрь, 591 номерлы боерыгы;<br>8. Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының “Энергия саклау өлкәсендәге программаларның формасына таләпләрне раслау һәм дәүләт һәм муниципаль берәмлек, җайга салына торган эшчәнлек төре алып баручы оешмалар катнашында оешмаларның энергетик нәтиҗәлелегн арттыру һәм аларны тормышка ашырганда хисап турында”, 2014 ел, 30 нчы июнь, 398 номерлы Боерыгы;<br>9. Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының “Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә максатчан күрсәткечләрнең күрсәткечен исәпләү методикасын раслау турында, шул исәптән каршы куела торган шартларда”, 2014 ел, 30 нчы июнь, 399 номерлы Боерыгы;<br>10. Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының “Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә төбәк һәм муниципаль программаларны тормышка ашыру буенча методик рекомендацияләрне раслау турында”, 2014 ел, 11 нче декабрь, 916 номерлы Боерыгы;<br>11. Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының “Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өчен натураль чагылышта энергетик ресурсларны куллану күләмен исәпләү-үлчәү юлы белән билгеләү методикасын раслау турында”, 2016 ел, 4 нче декабрь, 67 номерлы Боерыгы. |
| Программаның заказчысы | МКУ «Исполнительный комитет Высокогорского муниципального района Республики Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ |
| Программаны эшләүче | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУМКУ «Исполнительный комитет Высокогорского муниципального района Республики Татарстан» |
| Программаның максатлары һәм бурычлары, төп максатчан | Биектау муниципаль районында тормыш сыйфаты, җитештерелә торган продукциянең конкурентлыгы тайпылусыз үскән вакытта, энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү белән нәтиҗәле идарә системасын формалаштыру |

| | |
|---|---|
| индикаторлар һәм күрсәткечләр | |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2019–2023 еллар |
| Төп чараларны башкаручылар | Җирле үзидарә органнары, җайга салына торган эшчәнлек алып бара торган оешмалар, ТКХ оешмалары, идарә компанияләре, торак йортларның милекчеләре, бюджет учреждениеләре, энергия ресурсларын башка кулланучылар |
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Барлык чыганаклар хисабына Пограмманы финанслауның гомуми күләме – 116 млн сум,<br>шул исәптән, Биектау районының берләштерелгән бюджеты чаралары хисабына (өстәмә керемнәр булган очракта) – 2,5 млн.сум;<br>РФ һәм ТР бюджетлары хисабына – 65,5 млн.сум;<br>бюджеттан тыш чыганаклар хисабына – 48 млн. сум;<br>*шул исәптән энергия ресурсларын кулланучылар хисабына – 17,5 млн. сум*<br>*- финанслау күләмнәренә уздырылган конкурслар нәтиҗәләре буенча корректировка уздырылырга тиешле һәм ел саен чираттагы финанс елына Биектау муниципаль районының берләштерелгән бюджетын формалаштырганда тәгаенләнәләр |
| Программаны тормышка ашырудан көтелгән ахыргы нәтиҗәләр | - икътисад секторларында энергия куллану нәтиҗәлелеген арттыруның тотрыклы процессын тәэмин итү;<br>- энергия саклауны стимуллаштыру механизмнарын камилләштерү һәм барлык дәрәҗә кулланучыларның энергетик нәтиҗәлелеген арттыру;<br>- энергия саклау потенциалын кулланыла торган электр энергиясе, җылылык энергиясе, табигый газ, су һәм күрсәткечләрен киметү юлы белән ныгыту һәм күрсәтелгән энергия ресурсларыннан югалтуларны киметү;<br>- муниципаль учреждениеләрне энергетик ресурслар белән тәэмин итүгә бюджет чыгымнарын киметү;<br>- халык һәм башка кулланучылар төркеме арасында энергия һәм ресурсларны саклау пропагандасы;<br>- җитештерү, транспортировкалау, саклау һәм куллану процессында ягулык-энергетика ресурсларын үлчәү һәм хисабын алып баруның төгәллеген, дөреслеген һәм бердәйлеген тәэмин итү. |
| Программаны тормышка ашыруда | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, тармак министрлыклары һәм ведомстволары, ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты. |

| | |
|---|---|
| контроль системасы | |

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Программа "Энергия саклау турында һәм энергетиканың нәтиҗәлелеген күтәрү хакында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында", 2009 ел, 23 нче ноябрь, 261-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында", 2003 ел, 6 нчы октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләп чыгарылган.

Әлеге Программада түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

**энергетик ресурс** – энергия йөртүче, хуҗалык һәм башка эшчәнлекне тормышка ашырганда кулланырга мөмкин булган яки кулланыла торган энергия, шулай ук энергия төре (җылылык, электр яки башка энергия төре);

**икенчел энергетик ресурс** – технологик процессны тормышка ашыру яки функциональ билгеләнеше билгеле энергетик ресурс төрен җитештерү белән бәйле булмаган җайланманы куллану нәтиҗәсендә җитештерү һәм куллану калдыклары яки өстәмә продукт буларак алынган энергетик ресурс;

**ягулык-энергетика ресурслары** – хуҗалык эшчәнлегендә кулланыла торган барлык үзгәртелгән табигый ягулык һәм энергия төрләренең барысы. Хәзерге вакытта кулланыла торган яки киләчәктә (файдалы) кулланырга мөмкин булган энергия йөртүчеләр;

**энергия саклау** – кулланыла торган энергетика ресусрларын күләмен киметүгә юнәлдерелгән, шул ук вакытта аларны куллануда билгеле файдалы нәтиҗәне саклаган хәлдә (шул исәптән, җитештерелә торган продукция, эшләнгән эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр күләме), оештыру, хокукый, техник, технологик, икътисади башка чараларны тормышка ашыру

**энергетик нәтиҗәлелек** – энергетик ресурсларны куллануда файдалы нәтиҗәнең, әлеге нәтиҗәне алу максатларында продукция, технологик процесс, юридик зат, шәхси эшмәкәргә карата булдырылган энергетик ресурсларның чыгымнарына чагыштырмасын күрсәтүче характеристика;

**энергетик нәтиҗәлелек классы** – энергетик нәтиҗәлелеген күрсәтүче продукциянең характеристикасы;

**көнкүреш энергия куллану җайланмасы** – функциональ билгеләнелеше энергетик ресусрларны куллануны күз алдында тота торган, куллана торган егерлеге электр энергиясе өчен егерме бер киловатт, җылылык энергиясе өчен йөз киловаттан артмаган һәм аны куллану шәхси, гаилә, йорт һәм башка төр шундый ихтыяҗлар өчен билгеләнә торган продукция;

**энергетик тикшерү** – кулланыла торган энергетика ресусрлары күләме турында дөреслеккә туры килгән мәгълүмат алу максатларында энергетика ресурсларын куллану турында, энергетик нәтиҗәлелек турында, энергия саклау мөмкинлекләрен ачыклау һәм энергетик паспортта алынган нәтиҗәләрне күрсәтеп, энергетик нәтиҗәлелекне арттыру турында мәгълүматны җыю һәм эшкәртү;

**энергия хезмәте күрсәтү шартнамәсе (контракт)** – башкаручы тарафыннан энергия саклау һәм заказчы тарафыннан энергетика ресурсларын куллануның энергетик нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән гамәлләр предметы булган шартнамә (контракт);

**муниципаль продукт** – ахыргы куллану өчен товарлар һәм хезмәтләр эшләп чыгару процессын характерлаучы, муниципаль берәмлекнең икътисади эшчәнлеген гомумиләштерүче күрсәткеч. Муниципаль продукт агымдагы бәяләрдә (номиналь), каршы куела торган бәяләрдә (реаль) исәпләнелә;

**дәүләт яки муниципаль берәмлек катнашында оешмалар** – устав капиталында Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлекнең өлеше (кертеме) илле проценттан да күбрәк булган һәм аларга карата Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек юридик затларның устав капиталларын тәшкил иткән, тавыш бирүче акцияләргә (өлешләргә) туры килгән гомуми тавышларның илле процентыннан да күбрәге белән турыдан-туры яки читләтеп идарә итәргә хокукы булагн юридик затлар, дәүләт яки муниципаль унитар предприятиеләр, дәүләт яки мунципаль учреждениеләр, дәүләт компанияләре, шулай ук мөлкәтләре яки акцияләренең яки устав капиталларында өлешләренең илле проценты дәүләт корпорацияләренеке булган юридик затлар;

**җайга салына торган эшчәнлек төре** - Россия Федерациясе законнары нигезендә, җайга салына торган бәяләр (тарифлар) кулланыла торган табигый монополияләр субъектлары, коммуналь комплекс оешмалары белән тормышка ашырыла торган эшчәнлек төрләре;

**күп фатирлы йортны карап тоту өчен җаваплы зат** – торак законнары нигезендә күп фатирлы йорт белән идарә итү йөкләмәләре йөкләнелгән зат;

**төзүче** – шәһәр төзелеше законнары нигезендә төзүче дип танылган зат;

**энергетик паспорт** – энергетик ресурслар куллану балансын, оешманың хуҗалык эшчәнлеге процессында аларны куллану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре, энергия саклау потенциалы, шулай ук энергия саклау чаралары турында мәгълүматлар;

**максатчан күрсәткеч** – регламентлаучы документлар белән чагыштырмача билгеләнгән җылылык-энергетика ресурсларын куллану нәтиҗәлелегенә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру буенча хуҗалык итүче субъектларның эшчәнлеган характерлаучы абсолют һәм чагыштырма күрсәткеч;

**энергия саклау потенциалы** – җылылык-энергетика ресурсларын (алга таба – ҖЭР) куллануны оптимальләштерү юлы белән энергетик нәтиҗәлелекне арттыру мөмкинлеген характерлаучы физик күрсәткеч. Потенциал билгеләнелгән (регламентлаучы документлар белән билгеләнгән), норматив (барлык системаның эш күрсәткечләрен норматив күрсәткечләргә китерү шарты белән), теоретик (модернизация һәм инновацион технологияләр кертү уздырганда);

**продукциянең энергия сыйдырышлыгы** – продукция эшләп чыгару өчен энергия тотуны (шартлы ягулык тоннасы) характерлауы күрсәткеч (млн.сум).

Программада түбәндәге кыскартылмалар кулланыла:

БМР - Биектау муниципаль районы;

ГВС – кайнар су белән тәэмин итү;

ТКХ – торак-коммуналь хуҗалык;

МКД – күп фатирлы йорт;

СРО – үзе җайга салына торган оешма;

ТСЖ – торак милекчеләре ширкәте;
ш. я. т. – шартлы ягулык тоннасы;
ЯЭР – ягулык-энергетика ресурслары.

## 2. Программаны тормышка ашыру өлкәсенә гомуми характеристика

Биектау районы Татарстан Республикасының төньяк-көнбатышында урнашкан, Казан шәһәренә төньяк-көнчыгыштан килеп тоташа. Районның төньяк чиге Мари-Эль Республикасы һәм Әтнә районы белән, көнбатыштан – Яшел Үзән районы, көньяктан һәм көнчыгыштан Татарстан Республикасының Питрәч һәм Арча районнары белән чиктәш. Биектау районы Казан шәһәренең шәһәр яны булып тора, аның белән тимер юл һәм автомобиль юлы белән тоташа һәм шәһәр чигенә кадәр 15 минут машина белән барырлык арада.

Биектау авылы - Биектау муниципаль районының административ үзәге, Казан шәһәреннән төньяк-көнчыгышка 17 км да урнашкан. Биектау авыл җирлегенең халкы 16,4 мең кешенең тәшкил итә. Биектау авылыннан 1,5 км ераклыкта, Татарстан Республкасының көнбатыш районнарын һәм көнчыгыш районнарын транспорт агымнары белән тоташтыручы, шулай ук Киров өлкәсе һәм Удмуртия Республикасы белән бәйләүче Казан-Әгерҗе линиясендә Биектау тимер юл станциясе урнашкан.

1574,25 мең кв.км территориясе булган Биектау муниципаль районы территориясендә (Татарстан Республикасы гомуми мәйданының 2,5%) 50 меңнән артык кеше яши (республиканың гомуми халкыннан 1,3%), торак пунктлар – 124, алар 25 авыл җирлегенә берләштерелгән.

Биектау районының аеруча да эре сәнәгать предприятиеләре булып торалар – “Татспиртпром” АҖ, “Усад спирт заводы” һәм “Ликер, аракы эшләнмәләре заводы”, “Винербергер Коркачык” ҖЧҖ кирпеч заводы, “Сафпласт” ҖЧҖ, “Татагролизинг” ААҖ, Исләйтар урманчылыгы һ.б.

2018 елда район авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренең товар продукцияләрен җитештерү өлеше тулаем төбәк продуктында 14,3%ны тәшкил итте. Районда язгы бодай, көзге арыш, солы, яшелчәләр, бәрәңге игелә. Терлекчелекнең төп өлкәләре – сөт-ит терлекчелеге. Районның иң эре предприятиеләре булып саналалар - “Бөреле” ЯАҖ, “Серп и молот” ҖЧҖ, “Правда” ҖЧҖ, “Битаман” ҖЧҖ, “Ватан” авыл хуҗалыгы предприятиесе ҖЧҖ.

Биектау муниципаль районында мәгариф өлкәсе 73 мәгариф учреждениесе белән тәкъдим ителгән. 18 урта, 8 төп һәм 6 башлангыч мәктәп, 38 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, шулай ук 3 өстәмә белем бирү учреждениесе бар.

Районда 79 мәдәният учреждениесе эшләп килә, шул исәптән район Мәдәният йорты, 35 авыл мәдәният йортлары һәм клублар, 38 китапханә, 2 музей, 3 музыка мәктәбе.

Район халкына медицина ярдәмен 134 койка-урынлы стационары булган Биектау үзәк район хастаханәсе күрсәтә. Үзәк район хастаханәсе составында 15 койкалы Дөбъяз участок хастаханәсе, 5 табиб амбулоторияләре, 47 фельдшер-акушер пунктлары эшли.

Районның административ-территориаль төзелеше аның энергетика ресурсларын куллануда  Биектау авылы, Биектау тимер юл станциясе бистәсе, Дөбъяз, Коркачык, Бөрелек җәнлек совхозы авылларында төп кулланучылар булуы белән характерлана. Биектау авылында җылылык энергиясе белән төп тәэмин итүче, су белән тәэмин итү, су чыгару һәм чыгарылган суны чистарту буенча хезмәтләрне күрсәтүче – “Биектау коммуналь челтәрләре” ААҖ. Районның энергия ресурсларына аеруча да күп экономия ясау резервлары Биектау авылында тупланган. Аерып әйткәндә, суны күтәрү һәм су бирүгә электр энергиясенә чыгымнар, суны чыгару һәм чыгарган суны чистарту, торак секторын җылыту өчен коммуналь казаннар тарафыннан газны куллану, социаль һәм сәнәгать объектлары, челтәрләрдә җылылык энергиясен югалту һ.б. Энергия саклауда нәкъ шундый ук потенциал районның сәнәгать өлкәсендә, җылылык-энергетика хуҗалыгында да бар.

2019 елның 1 нче гыйнварына Биектау муниципаль районының торак фондында күпфатирлы йортларда фатирлар саны  - 8858. Торак фондының гомуми мәйданы 1508,9 мең кв. метрны тәшкил итте, шулардан шәхси милектә – 1401, 6 мең кв. метр, гомуми мәйданнан 92.9%.

Ахыргы куллануда энергетика ресурсларын Биектау муниципаль районы буенча куллану потенциалына бәя бирелә:

җылылык энергиясе буенча – 20 – 25 %;

электр энергиясе буенча – 14 – 16 %;

су буенча – 14 – 16 %.

Торак биналарны җылыту өчен энергетика ресурсларының төп чыгымнарына килгәндә (шул исәптән күпфатирлы йортлар), халыкны җылы су белән тәэмин итү, бюджет учреждениеләрен җылыту-вентиляция ихтыяҗлары, эчке һәм урам утлары.

Энергетика ресурсларын куллануны киметүнең негатив ягы булып, җайга салына торган эшчәнлекне тормышка ашыручы (җылылык белән тәэмин итүче оешмалар һәм суүткәргеч-канализация хуҗалыгы оешмалары) оешмаларга кагылырга мөмкин булган күләмнәрне киметүнең тискәре нәтиҗәсе тора, ә бер берәмлек хезмәт өчен  чагыштырма чыгымнарны арттыру хисабына аларның хезмәтләренә бәя күтәрелсә – ахыргы чиктә кулланучыларга да кагыла. Куллану күләмнәрен киметүнең тискәре нәтиҗәсен юк итү өчен җайга салуның дәүләт һәм муниципаль органнары тарафыннан тәэмин итүчеләргә кулланучылар өчен энергетика ресурсларына бәяне куйганда, тәэмин итүчеләр мәнфәгатьләрен дә, энергетика ресурсларын кулланучыларны да уйлап балансга тотарга кирәк.

## 3. Программаның максатлары, бурычлары. Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары

2019-2023 елларга Биектау муниципаль районында  энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлеген күтәрү муниципаль программасының төп максатын түбәндәге рәвештә формалаштырырга була:

Биектау муниципаль районында тормыш сыйфаты, җитештерелә торган продукциянең конкурентлыгы тайпылусыз үскән вакытта, энергия саклау һәм

энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү белән нәтиҗәле идарә системасын формалаштыру.

Әлеге Программаның база бурычлары:

- икътисад секторларында энергия куллану нәтиҗәлелеген арттыруның тотрыклы процессын тәэмин итү;

- энергия саклауны стимуллаштыру механизмнарын камилләштерү һәм барлык дәрәҗә кулланучыларның энергетик нәтиҗәлелеген арттыру;

- энергия саклау потенциалын кулланыла торган электр энергиясе, җылылык энергиясе, табигый газ, су һәм күрсәткечләрен киметү юлы белән ныгыту һәм күрсәтелгән энергия ресурсларыннан югалтуларны киметү;

- муниципаль учреждениеләрне энергетик ресурслар белән тәэмин итүгә бюджет чыгымнарын киметү;

- халык һәм башка кулланучылар төркеме арасында энергия һәм ресурсларны саклау пропагандасы;

- җитештерү, транспортировкалау, саклау һәм куллану процессында ягулык-энергетика ресурсларын үлчәү һәм хисабын алып баруның төгәллеген, дөреслеген һәм бердәйлеген тәэмин итү.

- электр энергиясен, җылылык энергиясен һәм суны куллануның чагыштырма күрсәткечләрен киметү, шул исәптән бюджет учреждениеләре тарафыннан барлык энергетика ресурсларын куллануны 2023 елга 10%тан да ким булмаган күләмгә киметү (2019 елдан ел саен 2%тан ким түгел).

Программаның төп индикаторлары 2023 елга кадәр чорда билгеләнгән.

## 4. Проблеманы хәл итүнең төп юллары

Торак фондта һәм Биектау муниципаль районының бюджет учреждениеләрендә энергия куллану буенча беренчел мәгълүматларны анализлау, энергетика ресурсларын эшләп чыгару һәм куллануның гомумиләштерелгән картинасын күрергә, ЯЭРын кулланучылар тарафыннан су, электр һәм җылылык энергиясен, табигый газ куллануның нәтиҗәлелегенә бәя бирергә мөмкинлек бирде.

Программаны эшләп чыгару процессында муниципаль район буенча түбәндәге кулланучылар төркемендә энергетика ресурсларын куллану буенча (һәрбер энергетика ресурсы буенча аерым) мәгълүматларны анализлау уздырылды:

- бюджет өлкәсе;
- торак фонды;
- коммуналь хуҗалык.

Ягулык-энергетика ресурсларын куллануның гомуми структурасында электр энергиясе, җылылык энергиясе, газ һәм су куллану аерып алынды.

Җыеп алынган мәгълүматларны анализлау нигезендә ЯЭР куллануның гомуми район структурасы формалаштырылды, 2023 елга кадәр БМР энергетика ресурсларын тоту динамикасы билгеленелде, аларны куллану буенча җыелма мәгълүматлар исәпләнелде.

Программа бурычлары белән тормышка ашыру буенча куелган беренче адымнарның иң ачыгы – төп энергетика ресурсларын куллануның коммерцияле

исәбен 100%ка алып баруга күчү. Бүгенге көндә Россия шартларында коммерцияле исәпкә күчү практикасы энергетика ресурслары өчен түләүгә чыгымнарның экономиясен якынча 10-12% ка гарантияли, бу тагын да төгәлрәк итеп исәпләү, шулай ук кулланучыларны энергия куллануны киметүне стимуллаштыру хисабына.

Энергетика ресурсларын җибәрү күләменең өлеше, БМРторак фондының күп фатирлы йортларында яшәүче халкы өчен хисап алып бару приборлары күрсәткечләре буенча куела торган счетлар 2019 елның 1 нче гыйнварына тәшкил итәләр:

- электр энергиясе – 100 %;
- җылылык энергиясе – 18,2 %;
- салкын су – 96,6 %;
- табигый газ – 100 %.

"Энергия саклау турында һәм энергетиканың нәтиҗәлелеген күтәрү хакында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында", 2009 ел, 23 нче ноябрь, 261-ФЗ номерлы Федераль закон белән төрле категория кулланучыларны энергетик тикшерү (энергоаудит) уздыру күз алдында тотыла, шул исәптән вакыт-вакыт энергетик тикшерү уздыру мәҗбүри булган җирле үзидарә органнары, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр, энергетика ресурсларын эре кулланучыларны. Энергоаудит һәм кулланучыларның энергетик паспортларын төзү буенча чаралар әлеге Программа кысаларында күз алдында тотыла.

Оешмаларның энергетик нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән, җайга салына торган эшчәнлек төрен тормышка ашыручы, конкрет техник/технологик проектларны эшләп чыгару һәм тормышка ашыру өчен җаваплылык, турыдан-туры күрсәтелгән энергия һәм ресурс белән тәэмин итүче оешмаларга йөкләнә. Әлеге чараларны кертү турында карар, аларның энергетик тикшерүләре нәтиҗәләре буенча да кабул ителә, ә аларны уздыру өчен чыгымнар җайга салучы органнар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәт төрләренә тарифлар урнаштырганда исәпкә алына дип күз алдында тотыла.

Техник карарлардан кала, Программа энергия куллануны киметүне стимуллаштыручы, кулланучылар арасында энергетика ресурсларын саклау идеяләрен актив пропагандалауны оештыру, икътисади, хокукый һәм административ чаралар комплексын да күз алдында тота. Әлеге эш гаять мөһим, чөнки, практика күрсәткәнчә, гадәти кулланучыларның энергетика ресурсларын кулланудан файда күрүне тану, аларны энергия саклауга этәрүче саллы фактор булып тора.

### 5. Программаны тормышка ашыру нәтиҗәләренә бәя бирү индикаторлары исемлеге

"Энергия саклау өлкәсендә төбәк һәм муниципаль программаларга таләпләр һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру турында", 2009 ел, 31 нче декабрь, 1225 номерлы РФ Хөкүмәте карары нигезендә, энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә муниципаль программалар энергия саклау һәм

энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә максатчан күрсәткечләр исемлеген үз эченә алырга тиеш.

5.1 таблицасында 2019-2023 елларга Биектау муниципаль районында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә Программа белән билгеләнгән энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә планлаштырыла торган максатчан күрсәткечләр тәкъдим ителгән.

Күрсәткечләр динамикасын (үзгәрүен) сурәтләүче максатчан күрсәткечләр 2018 елның билгеле күрсәткечләренә чагыштырма буларак исәпләнеләләр, ә энергетика ресурслары исәбен алып бару приборлары белән җиһазландырылу максатчан күрсәткечләре энергия белән тәэмин итү инфраструктурасына тоташтырылган объектларга чагыштырмада исәпләнеләләр.

Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә максатчан күрсәткечләрне каршы куючы шартларда исәпләгәндә шул исәптән исәпкә алындылар, программа чаралары уздыру белән бәйле булмаган энергетик ресурсларны куллану структурасы һәм күләмнәренең объектив үзгәрү фаразлары.

Программаның максатчан күрсәткечләре

5.1 нче таблица

| № | Күрсәткечләрнең, күрсәткечләр төркеменең исеме | Үлчәү берәмлеге |
|---|---|---|
| **Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә гомуми максатчан күрсәткечләр** | | |
| 1. | Муниципаль продуктның энергия егәрлеге динамикасы | кг ш.я./ мең сум |
| 2. | Исәпләү приборларын кулланып исәпләүләр алып барыла торган электр энергиясе күләмнәре өлеше | % |
| 3. | Исәпләү приборларын кулланып исәпләүләр алып барыла торган җылылык энергиясе күләмнәре өлеше | % |
| 4. | Исәпләү приборларын кулланып исәпләүләр алып барыла торган су күләме өлеше | % |
| 5. | Исәпләү приборларын кулланып исәпләүләр алып барыла торган табигый газ күләме өлеше | % |
| 6. | Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү буенча чараларны финанслау өчен кулланыла торган бюджеттан тыш чаралар күләме, муницьпаль программаны финанслауның гомуми күләмендә | % |
| 7. | Кабат булдырыла торган энергия чыганакларын яки икенчел энергетик ресурсларны кулланып энергетика ресурсларын җитештерү күләмен үзгәртү | ш. я. т. |
| 8. | Кабат булдырыла торган энергия чыганакларын яки икенчел энергетик ресурсларны кулланып булдырылган энергетика ресурсларының өлеше | % |
| **Аерым төр энергетика ресурслары буенча экономияне күрсәтүче максатчан күрсәткечләр** | | |
| 1. | Натураль чагылышта электр энергиясе экономиясе | мең кВтч |
| 2. | Бәя чагылышында электр энергиясе экономиясе | мең сум |
| 3. | Натураль чагылышта җылылык энергиясе экономиясе | мең Гкал |
| 4. | Бәя чагылышында җылылык энергиясе экономиясе | мең сум |
| 5. | Натураль чагылышта су экономиясе | мең.м.куб |
| 6. | Бәя чагылышында су экономиясе | мең сум |
| 7. | Натураль чагылышта табигый газ экономиясе | мең.куб.м. |
| 8. | Бәя чагылышында табигый газ экономиясе | сум |
| **Бюджет секторында максатчан күрсәткечләр** | | |

| № | **Күрсәткечләрнең, күрсәткечләр төркеменең исеме** | **Үлчәү берәмлеге** |
|---|---|---|
| 1. | Исәпләү приборларын кулланып түләү тормышка ашырыла торган җылылык, электр энергиясе, су өчен чыгымнарның чагыштырмасы | Гкал/кв.м, кВтч/кеше, куб.м./кеше |
| 2. | Исәпләү методларын кулланып тормышка ашырыла торган җылылык, электр энергиясе, су өчен чыгымнарның чагыштырмасы | Гкал/кв.м, кВтч/кеше, куб.м./кеше |
| 3 | Исәпләү приборларын кулланып түләү тормышка ашырыла торган җылылык, электр энергиясе, су өчен чыгымнарның чагыштырмасы үзгәрү | Гкал/кв.м, кВтч/кеше, куб.м./кеше |
| 4. | Исәпләү методларын кулланып түләү тормышка ашырыла торган җылылык, электр энергиясе, су өчен чыгымнарның чагыштырмасы үзгәрү | Гкал/кв.м, кВтч/кеше, куб.м./кеше. |
| 5. | Җылылык, электр энергиясе, су өчен чыгымнары чагыштырмасының, исәпләү приборлары кулланып исәпләүләр тормышка ашырыла торганына чагыштырмасына үзгәрүе | - |
| 6. | Исәпләү приборларын кулланып түләү тормышка ашырыла торган электр энергиясе, җылылык энергиясе, су, табигый газ өчен күләмнәре өлеше | % |
| 7. | Бюджет учреждениеләрен энергетик ресурслар белән тәэмин итүгә муниципаль бюджеттан чыгымнар өлеше | % |
| 8. | Бюджет учреждениеләрен энергетика ресурслары белән тәэмин итү өчен муниципаль бюджетның чыгымнары динамикасы | мең сум |
| 9. | Ягулык алу өчен коммуналь комплекс оешмаларына субсидияләр тәкъдим итү өчен муниципаль бюджетның чыгымнары өлеше | % |
| 10. | Ягулык алу өчен коммуналь комплекс оешмаларына субсидияләр тәкъдим итү өчен муниципаль бюджетның чыгымнары динамикасы | мең сум |
| 11. | Мәҗбүри энергетик тикшерү уздырылган, муниципаль бюджет хисабына финанслана торган бюджет учреждениеләре өлеше | % |
| 12. | Муниципаль заказчылар белән төзелгән энергия хезмәте шартнамәләре саны | шт. |
| 13. | Энергия хезмәте шартнамәләре төзелгән дәүләт, муниципаль заказчылар өлеше | % |
| 14. | Энергетика нәтиҗәлелеге таләпләре нигезендә муниципаль ихтыяҗлар өчен сатып алына торган товарлар, эшләр, хезмәтләр өлеше | % |
| 15. | 1 кешегә торак биналар һәм коммуналь хезмәтләрне түләү өчен гражданнарга социаль ярдәм күрсәтүгә муниципаль бюджеттан чагыштырма чыгымнар | мең сум/ кеше |
| | **Торак фондында максатчан күрсәткечләр** | |
| 1. | Исәпләү приборларын кулланып исәпләүләр тормышка ашырыла торган (коллектив, шәхси), торак йортларда кулланыла торган (шәхси һәм күп фатирлы) электр энергиясе, җылылык энергиясе, су, табигый газ күләмнәре өлеше | % |
| 2. | Энергетик тикшерү уздырылган торак йортлар саны | шт. |
| 3. | Исәпләү приборларын кулланып исәпләүләр тормышка ашырыла торган, торак йортларда кулланыла торган (шәхси һәм күп фатирлы) электр энергиясе, җылылык энергиясе, су, табигый газ чыгымнары чагыштырмасы | Гкал/кв.м, кВтч/кеше, куб.м./кеше, тыс.куб.м./кв.м. |
| 4. | Исәпләүләр кулланып тормышка ашырыла торган, торак йортларда кулланыла торган (шәхси һәм күп фатирлы) электр энергиясе, җылылык энергиясе, су, табигый газ чыгымнары чагыштырмасы | Гкал/кв.м, кВтч/кеше, куб.м./кеше, мең куб.м./кв.м. |
| 5. | Исәпләү приборларын кулланып исәпләүләр тормышка ашырыла торган, торак йортларда кулланыла торган (шәхси һәм күп фатирлы) электр энергиясе, җылылык энергиясе, су, табигый газ чыгымнары чагыштырмасы үзгәрү | Гкал/кв.м, кВтч/кеше, куб.м./кеше, тыс.куб.м./кв.м. |

| № | Күрсәткечләрнең, күрсәткечләр төркеменең исеме | Үлчәү берәмлеге |
|---|---|---|
| 6. | Исәпләүләр (норматив куллану) кулланып тормышка ашырыла торган, торак йортларда кулланыла торган (шәхси һәм күп фатирлы) электр энергиясе, җылылык энергиясе, су, табигый газ чыгымнары чагыштырмасы үзгәрүе | Гкал/кв.м, кВтч/кеше, куб.м./кеше, мең куб.м./кв.м. |
| **Коммуналь инфраструктура системасында максатчан күрсәткечләр** | | |
| 1. | Җылылык энегиясен эшләп чыгаруга ягулык чыгымы чагыштырмасы үзгәрү | кг ш.я./Гкал |
| 2. | Җылылык энергиясен биргәндә югалтулар күләме | Гкал |
| 3. | Су биргәндә югалтулар күләме | куб.м. |
| 4. | Су биргәндә (транспортировка) кулланыла торган электр энергиясе күләме үзгәрү динамикасы | кВтч |

# 6. Энергетик ресурсларны куллану характеристикасы

## 6.1. Биектау муниципаль районында җылылык белән тәэмин итү

### 6.1.1. Төп күрсәткечләр

Биектау муниципаль районы буенча бюджет секторының социаль учреждениеләренә җылылык энергиясен җибәрү буенча төп күрсәткечләр 6.1.1.1. таблицасында китерелгән. Җылыту өчен җылылык энергиясенең төп өлеше район мәгариф (мәктәп, балалар бакчалары) һәм сәламәтлек саклау учреждениеләренә (ҮРХ) туры килә. Биектау муниципаль районының күп фатирлы йортларына җылы су белән үзәкләштерелгән тәэмин итү юк.

2018 елда БМР бюджет учреждениеләре тарафыннан җылылык энергиясен куллану

6.1.1.1 нче таблица

| Күрсәткечләр | Медицина учреждениеләре | Мәктәпләр | Балалар бакчалары | Башкалар |
|---|---|---|---|---|
| Объектлар саны – барлыгы (җылыту көч. белән > 0,2 Гкал/ч) | 1 (1) | 2 (0) | 3 (0) | 1(1) |
| *шул исәптән кайнар су белән тәэмин итү* | - | - | - | - |
| Җылылык өчен җылыту куллану (Гкал/ел) | 1 551,5 | 1 468,13 | 1359,55 | 10,02 |
| Кайнар су белән тәэмин итү өчен җылыту куллану (Гкал/ел) | - | - | - | - |
| Вентиляциягә җылыту куллану (Гкал/ел) | - | - | - | - |
| **Җылыту куллану барлыгы (Гкал/ел)** | **1 551,5** | **1 468,13** | **1359,55** | **10,02** |

Биектау районының 267 күпфатирлы йорты шәхси җылыту системасы белән җиһазландырылган, шул исәптән, бер һәм ике контурлы газ казаннары белән. 12 күпфатирлы йорт “Биектау коммуналь челтәрләре” ААҖ, “Жилстрой” ҖЧҖ коммуналь казаннарыннан үзәкләштерелгән җылылык системасына кушылган, аларда җылылык энергиясен исәпләү төеннәре урнаштырылган.

### 6.1.2. Биектау муниципаль районында җылылык белән тәэмин итү системасы

Торак-коммуналь секторы кулланучыларын, бюджет учреждениеләрен һәм башка җылылык энергиясен кулланучыларның ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен районда  100 кВтдан артык егәрлекле 10 газ котельныйлары бар. Шулардан 5 котельныйга һәм 2,18 км җылылык челтәрләренә “Биектау коммуналь челтәрләре” ААҖ махсуслаштырылган оешмасы тарафыннан хезмәт күрсәтелә.

Кулланучылар категорияләре буенча җылылык энергиясен куллану структурасы

6.2.1 рәсеме




“Биектау коммуналь челтәрләре” ААҖ эшләп чыгара торган җылылык энергиясен төп кулланучылар булып, Биектау авылының күп фатирлы торак фондында яшәүче халык тора. “Биектау коммуналь челтәрләре” ААҖ эшчәнлеге җылылык энергиясен җибәрү өлешендә, билгеле тарифларны урнаштырып, җайга салына торган булып санала.

“Биектау коммуналь челтәрләре” ААҖ котельныйларының суммада җылылык егәрлеге 26,95 Гкал/ч. не тәшкил итә (резервтагы казан агрегатларын да исәпләп), кушылган йөкләнеш - 4,21 Гкал/ч, котельный предприятиеләренең уртача тулылыгы 15,6%тан артмый.

### 6.1.3. Биектау муниципаль районында җылылык белән тәэмин итүнең икътисади проблемалары

Районның җылылык энергетикасы хуҗалыгында төп проблемасы булып, Татарстан Республикасының күпчелек башка районнарында кебек кулланучыларның шәхси җылыту системаларына китеп, үзәкләштерелгән җылылык белән тәэмин итүгә

сорау кимү, чагыштырмача югары физик яктан тузган казан җиһазлары, шулай ук тузган җылылык челтәрләре булу тора. Гамәлдәге котельныйларда RS, КЧМ, КВГ тибындагы казаннар урнаштырылган, аларның кайберләре хәзерге заман энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә туры килми, яну куркынычсызлыгы автоматикасы гамәлдәге таләпләргә җавап бирми, казанга кадәр суны эшкәртү кечкенә котельныйларда юк, бу аларның файдалы эш коэффициентын киметә һәм казаннарның вакытыннан алда сафтан чыгуына китерә.

Алда әйтелгәннәрне исәпкә алып, районда актив рәвештә күпфатирлы торак йортлардагы җылытуны шәхси ике контурлы казаннарга күчерү тормышка ашырыла, моның нәтиҗәсендә торак-коммуналь предприятиеләр тарафыннан җылылык энергиясен куллану күләмнәре кими, ә кайбер котельныйлар кулланылыштан чыга.

## 6.2. Биектау муниципаль районында су белән тәэмин итү

### 6.2.1. Төп күрсәткечләр

Биектау муниципаль районы буенча хуҗалык һәм эчәр өчен суны еллык куллану 1,77 млн. куб. м. ны тәшкил итә, шул исәптән :

- халык – 1,53 млн. куб.м. (86,4%);
- бюджет учреждениеләре – 0,1 млн. куб.м. (5,6%);
- башка кулланучылар – 0,14 млн. куб.м. (7,9%).

Районның күпчелек торак пунктларында су белән тәэмин итү, авыл җирлеге органнарына караучы үз артезиан скважиналарыннан тормышка ашырыла. Шул ук вакытта өй хуҗалыклары буенча шәхси суны исәпкә алуны, нигездә, оештырырга мөмкин түгел һәм халык, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре, фактта бары тик күтәрү һәм кудыру өчен электр энергиясе кулланыла торган өлеш өчен генә түлиләр. Карала торган район халкы тарафыннан суны куллану күләмнәре шулай ук белешмә рәвешендә Программада китерелгән һәм булган статистик мәгълүматлар нигезендә исәпләнелгән.

Кулланучылар категорияләре буенча суны куллану структурасы

6.2.1.1 рәсеме




Биектау районы халкы өчен үзәкләштерелгән су белән тәэмин итүгә уртача тарифлар 2018 ел – 19,12 сум / $м^3$, 2017 ел – 18,71 сум/$м^3$.

### 6.2.2. Биектау муниципаль районының су белән тәэмин итү системасы

Биектау авылында төп су белән тәэмин итү чыгынаклары булып артезиан скаважиналары тора. Кулланучыларга хуҗалык һәм эчү өчен суны күтәрү, чистарту һәм транспортировкалау буенча хезмәтләрне тәэмин итүчеләр булып торалар:

- Биектау авылында – "Биектау коммуналь челтәрләре" ААҖ;

- Бимери авылында, Бөреле җәнлек совхозында - – "Бөреле коммуналь челтәрләре" ЯАҖ;

- Коркачык, Шәпше авылларында – «Коркачык коммуналь предприятиесе» ЯАҖ;

- Дөбъяз авылында – "Биектау коммуналь челтәрләре" ААҖ.

Биектау районы коммуналь сууткәргечләре челтәрләрендәге су микробиология һәм санитар-химик күрсәткечләр буенча гигиена нормативларына туры килә.

### 6.3. Биектау муниципаль районында электр белән тәэмин итүнең төп күрсәткечләре

Биектау муниципаль районында электр белән тәэмин итү "Татэнергосбыт"ААҖ тарафыннан "Сетевая компания" ААҖ Биектау электр челтәрләре Биектау РЭЧ челтәрләре буенча тормышка ашырыла.

Биектау муниципаль районы буенча электр энергиясен гомуми куллану 2018 елда – 183,172 млн. кВт*ч, шул исәптән :

- халык – 76,34 млн. кВт*ч;

- социаль өлкә бюджет учреждениеләре һәм җирле үзидарә органнары – 12,46 млн. кВт*ч;

*шул исәптән урамны яктырту – 4,028 млн. кВт*ч;*

- сәнәгать – 51,93 млн. кВт*ч;
- авыл хуҗалыгы – 10,98 млн. кВт*ч;
- башкалар – 31,46 млн. кВт*ч.

БМР буенча электр энергиясен куллану структурасы

6.3.1 рәсем




## 6.4. Биектау муниципаль районында газ белән тәэмин итүнең төп күрсәткечләре

Биектау районы буенча табигый газ куллану структурасы

6.4.1 рәсем



Биектау муниципаль районы кулланучылары өчен челтәрле табигый газ белән тәэмин итүче булып “Газпром межрегионгаз Казань” ЯАҖ тора.

2018 ел нәтиҗәләре буенча кулланыла торган газ күләме район буенча 111,367 млн. куб.м. тәшкил итте.

## 7. Энергетика ресурсларын куллануның коммерцияле хисабы системасын оештыру

Энергетика ресурслары хисабын оештыру һәрбер этапта (җитешетерү, бүлеп бирү, куллану) барлык энергия саклаучы чаралар өчен базалы башлангыч нокта булып тора.  Биектау районында этаплап исәп алып бару төеннәрен урнаштыру программасы кулланучылар тарафыннан энергетика ресурсларын түләүгә чараларны чынбарлыкта да экономия ясау мөмкинлеген күрсәтә,  ЯЭР куллану һәм җитештерү процессы катнашучыларын энергия саклауга матди стимуллаштыруга шартлар тудыра, шулай ук энергосистеманың югары югалтулар урыннарын ачыкларга һәм энергия саклау чараларын кертү нәтиҗәләрен контрольдә тотарга мөмкинлек тудыра.

Хәзерге вакытта бер БМР халкына уртача чагыштырма су куллану 100,11 л/тәү.не тәшкил итә, су кулланган өчен коммерцияле исәпләү приборы белән тәэмин ителү дәрәҗәсе, гомуми су куллланудан – 42%, калган кулланылган су өчен исәпләүләр, башлыча, расланган нормативлар буенча тормышка ашырыла. Тәҗрибә күрсәткәнчә, торак фатирларда һәм йортларда исәпләү приборлары урнаштыру чагыштырма су куллануны 10-15% яшәүнең уңайлылыгын киметмичә, киметүгә мөмкинлек бирә, моның өстенә челтәрләрдәге югалтулар күләменә дә бәя бирергә мөмкинлек туа, бу кулланучы оешмаларга су агып ятулар проблемасына аеруча да игътибар итәргә мөмкинлек тудыра.

Электр энергиясен куллану өлешендә БМР буенча шәхси һәм объектив исәпләү приборлары күрсәткечләре буенча җибәрү күләмнәре хәзерге вакытта 100%ны тәшкил итә. Ләкин, күрсәткечләрне куллану өчен үзара исәпләүләрдә кулланыла торган электр исәпләү приборларының бер өлеше (бигрәк тә иске биналарда һәм бюджет өлкәсендәге учреждениеләрдәгеләр), искергән бер тарифлы механик модельләр, тәүлек вакыты, бәйрәм һәм эш көннәреннән бәйлелектә торган тарифлар буенча дифференцияләнгән исәп алып бару мөмкин түгел.

Шәхси (фатирлар буенча) шәхси иәспләү приборларын кертү белән паралель рәвештә энергетика ресурсларын куллану исәбен алып бару коллектив (гомуми йорт) төеннәрен урнаштыру да урынлы. Шәхсиләрдән аермалы буларак, исәпләү алып баруның гомуми йорт төеннәре куллану күләмне генә түгел, ресурслар параметрлары сыйфатын да контрольдә тотарга мөмкинлек бирә (мәсәлән, җылылык энергиясе өчен – басым һәм температура), аларны тотмау, куллануның күләмнәре артуга китерергә мөмкин. Моның өстенә, гомуми йорт хисабын алып бару приборлары суның яисә җылылык энергиясенең тәэмин итүчедән йортка кадәр юлда ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар белән исәпләүләр алып барганда югалтуларын төгәлрәк ачыкларга, күп фатирлы йортны су һәм җылылык белән тәэмин итү системасында агып ятуларны ячыкларга, һәм гомумән, ресурсларны саклауга реаль мөмкинлекләр бирә.  Гомуми

йорт исәпләү приборын урнаштыру югалтулар урыннарын – йорт челтәрләрендә яки тәэмин итүче челтәрләре кишәрлегендә бетерергә мөмкинлек бирә.

Биектау районы кулланучыларының энергетика ресурсларын коллектив (йорт) һәм шәхси (фатир) коммерцияле исәпләү приборлары күрсәткечләре нигезендә тизләтелгән күчеше буенча эшләр күләме “Энергия саклау турында һәм энергетиканың нәтиҗәлелеген күтәрү хакында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында”, 2009 ел, 23 нче ноябрь, 261-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре нигезендә тормышка ашырыла.

Алда әйтелгәннәрне исәпкә алып, Биектау районында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү буенча муниципаль программа чараларының төп һәм беренчел блокы булып, 100% коммерцияле исәпкә күчү тора.

Энергетика ресурслары исәбен алуның коммерцияле исәбен алуга күчү буенча программаның актуальлеге бер төркем социаль һәм икътисади фаторлар белән билгеләнгән. Социаль факторлар күрсәтелә торган коммуналь хезмәтләр сыйфаты белән бәйләнгән, икътисади – халыкның коммуналь хезмәтләр өчен кыйбат түләүләре белән.

Энергетика ресурсларын тотуның исәбен алып бару шәхси исәпләү приборларын эксплуатацияләү вакытында сорауларның берсе – аларның ремонты һәм тикшерү, чөнки хәзерге вакытта йорт эчендәге инженер челтәрләрен һәм күп фатирлы йорт җайланмаларын карап тоту һәм ремонт уздыруга тарифларда исәпләү приборларын ремонтлау һәм тикшереп тотуга чаралар каралмаган. Әлеге тарифлар торак биналар милекчеләре тарафыннан расланырга тиеш. Моның өстенә, мәҗбүри тикшерүләр уздыру, исәпләү приборларын ремонтлау һәм алыштыру өчен районда кулланучыларга хезмәт күрсәтү өчен билгеле хезмәт күрсәтү хезмәте булырга тиеш.

## 8. Энергетика ресурсларын кулланганда энергия саклау

### 8.1. Торак йортларда энергия саклау

2019 елның 1 нче гыйнварына Биектау муниципаль районы торак фондында күпфатирлы йортларда фатирлар саны – 8858. Торак фондының гомуми мәйданы 1508,9 мең кв. метрны тәшкил итте, шулардан шәхси милектә 1401,6 мең кв. метр, гомуми мәйданнан 92,9%.

2019 елның 1 нче гыйнварына район халкының саны 50,5 мең кешене тәшкил итә (шул исәптән Биектау авыл җирлегендә – 16,4 мең кеше) һәм энергетика ресурсларын һәм суны эре кулланучылардан санала.

Читләтеп алган конструкцияләр материаллары буенча күп фатирлы йортлар түбәндәгечә бүленәләр: панель – 8,6%, кирпеч – 53,8 %, агач һәм катнаш - 31,6%, башкалар – 6%.

Биналарның тышкы диварларының җылылык саклау сыйфатлары югары түгел, бигрәк тә заманча җылылык саклау буенча таләпләргә туры килмәгән иске серияле корылмаларда (чикләүче конструкцияләр аркылы җылылык югалту 20-30%) һәм торак фондында җылылык энергиясен куллану күләменең югары дәрәҗәдә булуның төп сәбәбе булып торалар.

Күп фатирлы муниципаль торак фонды белән идарә итү Биектау авылында «Вавилон-Жилсервис» ҖЧҖ (111 күпфатирлы йорт), «Комфорт» ИК (112 күп фатирлы йорт) тарафыннан тормышка ашырыла, кайбер йортлар идарә формасы итеп ТСЖны сайладылар.

Торак биналарның энергетик нәтиҗәлелеген күтәрү өчен киңәш ителгән чаралар исемлеге түбәндәге эш төрләрен үз эченә ала:

- чик конструкцияләренең җылылык саклавын арттыру (шул исәптән иске тәрәзәләрне тәрәзәпакетларга алмаштыру, лоджий һәм балконнарны пыялалау);
- тишекләрне һәм тәрәзә һәм ишек ярыкларын томалау юлы белән һаваны инфильтрлау белән җылылык югалтуны киметү, керә торган ишекләргә доводчиклар кую;
- җылылык бирелми торган подвал һәм чормаларда җылылыкның эчке торбаүткәргеч системаларында җылылыкны изоляцияләү (җылылык изоляциясен торгызу);
- радиаторларның эчке өлешләрендәге һәм илтүче торбаүткәргеч системаларны реагент белән сүтеп алмыйча гына юып, утырмаларны бетерү хисабына гидравлик һәм җылылык югалтуларны киметү;
- балансы клапаннар белән җылылык куллануны җайга сала торган автоматлаштырылган җайга салу төеннәрен урнаштыру (җылылык йөкләнеше 0,2 Гкал/ч тән артмаган объектлар өчен);
- заманча энергия саклау яктырту җайланмалары, светодиодлар нигезендә подъезд эчендәге яктырту системаларын модернизацияләү;
- подъездларны яктырту системалары, баскыч төпләрен автоматлаштырылган җайга салу системалары белән җиһазландыру (хәрәкәт, биредә булу датчиклары).

Әлеге эшләрне комплексы итеп, аларга экономия ясауның аеруча да нәтиҗәле итү өчен, энергетика ресурслары исәбен алып бару йорт һәм фатир төеннәрен урнаштыру/алыштыру белән бергә башкару урынлы. Күрсәтелгән чаралар күпчелек күп фатирлы торак йортта массалы рәвештә уздырылырга мөмкин, чөнки алар Россиянең урта полосасында чынбарлыктагы шартларда нәтиҗәлелеккә тикшерү уздылар.

Торак секторында программа чараларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә энергетика ресурсларына экономиянең биелма күрсәткече 7.1.1. таблицасында китерелгән.

2019 ел һәм алдагы елларга энергетик нәтиҗәлелекне күтәрү буенча эшләр күләменә кертелергә тиешле торак йортларның адреслы исемлеген, билгеле эш төрләренә рөхсәте булган махсуслаштырылган оешмаларны да җәлеп итеп, энергетик тикшерү нәтиҗәләрендә формалаштырырга кирәк.

### 8.2. Бюджет өлкәсендә оешмаларда энергия саклау

2019 елның 1 нче гыйнварына Биектау районында түбәндәге муниципаль бюджет учреждениеләре эшләп килә:

